**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «МУСАБАЙ-ЗАВОД АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

# КАРАР

«24» сентябрь, 2019 ел Мусабай-Завод авылы № 48/8

Мусабай-Завод авыл җирлегендә җирле референдум үткәрүне билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 маддәләре, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 маддәсе, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20, 35 маддәләре, «Җирле референдум турында» 2004 елның 25 мартындагы 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 маддәсе, Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитетының 2019 елның 24 сентябрендәге 16 номерлы карары, Мусабай-Завод авыл җирлеге Советының 2019 елның 24 сентябрендәге 48/6 номерлы карары, Мусабай-Завод авыл җирлеге уставы нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2019 елның 24 ноябренә якшәмбе көнгә Мусабай-Завод авыл җирлегендә гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Мусабай-Завод авыл җирлеге Башкарма комитеты белән берлектә Мусабай-Завод авыл җирлегендә җирле референдум үткәрү турында инициативаны чыгарырга, җирле референдум сорауларын түбәндәгечә формалаштырырга::

«2018 елның 18 ноябрендә уздырылган үзара салым кертү мәсьәләсе буенча референдум нәтиҗәләре буенча кабул ителгән карар нигезендә авыл җирлеге бюджетына күчкән, Мусабай-Завод авылында янгын депосы төзүгә билгеләнгән гражданнарның калган үзара салым акчаларын түбәндәгеләргә кулланырга ризамы: Мусабай-Завод авылы зираты өчен койма сатып алу һәм урнаштыру; Ташкичү, Мусабай-Завод авылларында урам яктырткычларын ремонтлау».

3. Референдумны әзерләү һәм үткәрүне референдум комиссияләренә йөкләргә:

- муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясенә (Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы территориаль сайлау комиссиясе);

- Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Мусабай-Завод авыл җирлегенең участок сайлау комиссияләре.

4. Җирле референдум үткәрү белән бәйле чыгымнарны Мусабай-Завод авыл җирлеге бюджеты средстволары хисабына гамәлгә ашырырга.

5. Әлеге карарны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырырга.

6. Әлеге карарны җирлекнең мәгълүмати стендларында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырып, халыкка игълан итәргә.

7. Әлеге карар басылып чыккан көннән үз көченә керә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет рәисе Ф. Ә. Әгъләҗева